

**Оловянников Виктор Михайлович**
**Яшел Үзән медицина училищесының беренче директоры**

Виктор Михайлович 1933 елның 7 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. 1961 елда Казан дәүләт медицина институтын тәмамлый, аны тәмамлагач, берничә ел 1нче шәһәр сырхауханәсендә терапевт булып эшли.

Яшел Үзән медицина училищесы 1963 елның 18 июлендә ТАССР сәламәтлек саклау министрлыгының 1963 елның 18 июлендәге 370 номерлы боерыгы нигезендә ачыла. Училищеның директоры итеп 30 яшьлек Оловянников Виктор Михайлович билгеләнә. Яшел Үзән медицина училищесы өчен Чехов урамы, 2а йорт адресы буенча урнашкан элеккеге халык судының бер катлы агач бинасын бүлеп биргәннәр.

Штат составын нибары 6 кеше тәшкил итте: директор, завуч, өч укытучы һәм техник. «Аз сан булуга карамастан, коллектив бердәм, инициативалы булды», - дип искә ала ЗМУ директоры Оловянников В.М. «Дәреслекләр җитми иде, пособиеләр һәм муляжлар булмады. Студентлар белән бергә күрсәтмә материаллар: таблицалар, схемалар, рәсемнәр әзерләргә туры килде. Химия һәм микробиология кабинетлары өчен җиһазларны заводлардагы цехларда һәм лабораторияләрдә эзләдек һәм таптык. Коллегаларыбызның ныклыгы, хезмәт сөючәнлеге һәм оптимизмы аркасында гына без укыту-тәрбия процессын тиешле дәрәҗәдә оештыра алдык...».

1965 елда училище икенче бинага күчте, ул агач булса да, гомуми мәйданы 838 кв.м. булган ике катлы бина иде. 1978 елда училищеның Гоголь урамында урнашкан яңа бинага күчүе студентлар һәм бөтен педагогик коллектив өчен зур һәм шатлыклы вакыйга булды. «Без менә дигән уку корпусын алдык, анда һәр клиник фән буенча клиникага кадәр практика кабинеты, иркен спорт залы һәм уңайлы ашханә бар», - дип искә төшерә Виктор Михайлович.

Училищеның беренче директоры үз вазифаларын җаваплы һәм намус белән, югары профессиональ һәм мәдәни дәрәҗәдә башкара. Идарә карарларын нигезле кабул итә. Матди-техник базаны, финанс - хуҗалык эшчәнлеген, училищеның кадрлар потенциалын үстерүгә зур игътибар бирелде.

Үзенең хезмәт эшчәнлеге өчен Оловянников Виктор Михайлович берничә тапкыр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы мактау грамоталары белән бүләкләнде.